**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2019 елның «16» сентябреннән № 229

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында»**

Татарстан Республикасында педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм педагогик кадрларны беркетү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагог – хезмәткәрләргә- яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында" 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары нигезендә, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә, эшләнгән вакыт күләменә пропорциональ рәвештә, ай саен 1111 сум күләмендә, әмма бер педагогик хезмәткәргә - яшь белгечкә 1111 сумнан да артык булмаган стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләргә.

2. Оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының спорт министрлыгы булган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибен расларга.

3. Әлеге карар үз көченә 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары** **Р.Р. Фәсахов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
карары белән расланган
2019 елның «16» сентябреннән № 229

Оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының спорт министрлыгы булган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының спорт министрлыгы булган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү күләмен һәм тәртибен билгели. (алга таба – Оешма).

2. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба – тармак министрлыклары) тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр – яшь белгеч дип 30 яшькә кадәрге, югары белем бирү программалары – бакалавриат, специалитет, магистратура, аспирантура (алга таба – һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы) буенча дәүләт аккредитациясенә ия булган һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү оешмасын көндезге формада беренче тапкыр тәмамлаган һәм һөнәри белем бирү оешмасы яисә югары белем бирү мәгариф оешмасы тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча һөнәри белем бирү дәрәҗәсе һәм квалификациясе буенча Оешмага хезмәт шартнамәсе буенча эшкә кабул ителгән зат таныла.

4. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү хокукы түбәндәге оешмаларда бирелә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары;

гомуми белем бирү оешмалары;

ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар;

өстәмә белем бирү оешмалары.

5. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү педагогик вазифада өзлексез эшләүнең беренче өч ел дәвамында эшкә урнашу датасыннан башлап билгеләнә.

Педагог - яшь белгечләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар Оешма боерыгы белән раслана.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү алу өчен эшкә урнашу вакытын кичерүнең җитди сәбәпләре булып түбәндәгеләр тора:

документлар белән расланган вакытлыча эшкә сәләтсезлек;

Россия Федерациясе Хәрби Көчләрендә чакырылыш буенча вакытлы хезмәт үтү яки альтернатив граждан хезмәтен узу;

йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, балага 3 яшь тулганчы бала тәрбияләү буенча отпуск.

Ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик хезмәткәр – яшь белгеч вакытлыча эшкә яраксызлык тәмамланган көннән соң, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча вакытлы хезмәт, яки альтернатив граждан хезмәте үткәннән соң, йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, балага өч яшь тулганчы ял итү вакыты узганнан соң 60 көннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерсә билгеләнергә мөмкин.

7. Хезмәткәрне хәрби хезмәткә чакыруга яки хезмәткәрне альтернатив граждан хезмәтенә алыштыручы граждан хезмәтенә җибәрүгә бәйле хезмәт килешүе туктатылган очракта, ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик хезмәткәр – яшь белгеч Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча вакытлы хезмәт үткән, яисә альтернатив граждан хезмәте үткән көннән соң 60 көннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштергән очракта, өч еллык эш чоры чикләрендә яңадан билгеләнергә мөмкин.

8. Оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү түбәндәге периодта туктатылып торыла:

йөклелек һәм бала табу буенча отпуск вакытынеда, өч яшькә җиткәнче бала тәрбияләү буенча отпуск вакытында;

аспирантурада көндезге формада уку вакытында

9. Башка Оешмага педагогик вазыйфа буенча күчкәндә, 30 көннән дә артык булмаган вакыт аралыгында эштән китү рөхсәт ителә.

10. Педагогик хезмәткәр – яшь белгечне хезмәткәрләр саны яки штат кыскаруга бәйле рәвештә эштән чыгарганда, алга таба педагогик вазифага эшкә урнашканда, 60 көннән дә артык вакыт аралыгында эшләмәү рөхсәт ителә.

11. Айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013нче елның 8 нче августында 678 номерлы «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең вазыйфалары, җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында»гы карары белән расланган, вазыйфалары буенча педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларын башкаручы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләренең, белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасының 1 бүлегендәге 2 пункты нигезендә билгеләнә.

12. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен бирелә торган өстәмә түләү бары тик педагогик хезмәткәр -яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

13. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен бирелә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү төп педагогик вазыйфа һәм педагогик хезмәткәр – яшь белгеч тарафыннан эчке яраклашу шартларда башкарыла педагогик вазыйфа буенча билгеләнә.

14. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме атнасына (елга) педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән хезмәт хакы ставкасы буенча түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times H_f / H_n,$$

монда:

D – педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү атнасына (елга) педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән хезмәт хакы ставкасы күләме, ләкин 1 111 сумнан да артык булмаган;

P – педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә атнасына (елга) педагогик эш сәгате нормасы өчен 1111 сум күләмендә өстәмә түләү;

$H_f$ – педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$ – хезмәт хакының төп ставкасы өчен сәгатьләр нормасы.

15. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә күләме (ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр әлеге Тәртипнең 12 пункты белән билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән-яшь белгечләрдән тыш) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times t,$$

монда:

D – педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен, ләкин 1 111 сумнан да артык булмаган;

P – педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә стимуллаштыручы өстәмә түләү хезмәт хакы ставкасы өчен 1 111 сум;

t – эш алып бару сәгатьләренең (ставканың) факттагы саны.

16. Педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр исәбеннән түләнә.

17. Оешмалар, агымдагы елның 1 февраленә кадәр, Тармак министрлыкларына түбәндәге документларны тапшыралар:

Тармак министрлыклары тарафыннан расланган форма буенча ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен субсидия бирү турында гариза;

ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен акча бирү турында гаризага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

Тармак министрлыкларының боерыклары белән расланган форма буенча Оешманың яшь белгечләре – педагогик хезмәткәрләр реестрлары.

18. Тармак министрлыклары әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән документларны, кергән көннән башлап 10 эш көне өчендә карыйлар.

Оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки әлеге Тәртипнең 16 пункты таләпләренә туры килми торган документларның тапшырган очракта, Тармак министрлыклары документларны кире кайтара һәм биш көнлек срокта, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, Оешмага документлар пакетын кире кайтару турында хәбәр итә.

Документлар пакетын кире кайтару турында хәбәрнамә алынган көннән алып Оешма, әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән документларны, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, кабат тапшыра.

19. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләү өчен субсидияләр бирү турындагы Килешү нигезендә бирелә (алга таба - Килешү). Килешү Тармак министрлыгы һәм Оешма арасында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә төзелә.

Килешү әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килә торган документларны тапшырганнан соң 10 көн эчендә төзелә.

20. Тармак министрлыклары әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә, педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен түләнүче стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен субсидияләрне Оешмаларның шәхси счетларына квартал саен күчерәләр.

21. Оешмалар Тармак министрлыкларына педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә килешүдә каралган сроклар һәм форма буенча айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшыралар.

22. Оешма тарафыннан агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыклары билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиеш.

23. Оешма тарафыннан субсидия бирү шартларын бозганда, Тармак министрлыгының язма таләбе нигезендә субсидияләр күрсәтелгән таләп алынганнан соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

24. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән Килешүләрнең үтәлешен Тармак министрлыклары һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органнары контрольдә тота.

25. Оешмалар педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакын түләү вакытында ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне тәэмин итәләр.